РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.07.2024 № 108-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башлыгының 2015 елның 10 декабрендәге 178-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы вазыйфаи затларының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 09 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм вазыйфаи затлары тарафыннан шәхси кабул итү тәртибен раслау турында» 2015 елның 10 декабрендәге 178-п номерлы карары (Саба муниципаль районы Башлыгының 2018 елның 31 маендагы 90-п номерлы, 2020 елның 28 февралендәге 32-п номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктында «электрон документ рәвешендә» сүзләреннән соң «, шул исәптән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» (алга таба - Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып,» сүзләрен өстәргә»;

1.2. 7.2 пунктында «электрон адрес» сүзләрен «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланганда электрон почта адресы яисә шәхси кабинетның адресы (уникаль идентификаторы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 7.3 пунктында «электрон почта адресы» сүзләрен «, электрон почта адресы йә Бердәм порталда шәхси кабинет адресы,» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 14.9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда чираттан тыш шәхси кабул итүгә хокукка I, II төркем инвалидлар, инвалид балалар һәм шундый балаларны озатып йөрүче затлар ия.

Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына ия булалар:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм башка вәкилләр, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

3) I, II төркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм башка вәкилләр, әгәр алар инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) Өч яшькә кадәрге балалар белән кабул итүгә килгән гражданнар.»;

1.5. 18 пунктның 5 пунктчасын «күрсәтелгән электрон почта адресы буенча» сүзләрен «электрон почта адресы буенча йә күрсәтелгән Бердәм порталда шәхси кабинет адресы буенча» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 22.2 пунктта «электрон почта адресы» сүзләрен «, электрон почта адресы яисә Бердәм порталда шәхси кабинет адресы,» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә игълан итәргә.

Саба муниципаль районы
Башлыгы Р.Н.Минниханов